*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен олимпиада биремнәре**
***2017/2018 нче уку елы***

**X сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл -64**

**I. Берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Чагыштырмача озын сузыклар гына булган рәтне билгеләгез.
- [а], [о];
- [и], [ы];
- [у], [ә];
- [ө], [ү].

2. Күчерелмә мәгънәле сүзләр булган рәтне билгеләгез.
- ак бәхет; җыр сибү;
- өстәл ясау; кыяр үстерү;
- апа сүзе; малай тырышлыгы;
- көрәк сабы; исемлектә бишенче.

3. Фразеологик әйтелмәләрдән генә торган рәтне күрсәтегез.
- хәзинә табу; дөрес юл табу;
- таш күпер; күккә күтәрелү;
- авыз еру; уртак тел табу;
- сыбызгы сызгырту; базарга бару.

4. Ясагыч кушымча белән ясалган сүзләр рәтен билгеләгез.
- бәрәңге, көзгегә, җирләр;
- ефәктәй, кышкы, күтәренке;
- укытучы, укучы, язучы;
- чират, чирәм, читкә.

5. Ясалу төрләре (ысуллары) иң аз булган сүз төркемен табыгыз.

- фигыльләр;
- исемнәр;
- сыйфатлар;
- рәвешләр.

6. Түбәндәге сүзләрнең кайсысы кешегә карата кулланылмый?

- күркәм;
- чибәр;
- ямьле;
- юмарт.

7. Ясагыч кушымчасы булмаган сүзләр рәтен күрсәтегез.

- күзләр, балакай, яшьлек, тормыш;
- карга, язгы, эшчән, килгән;
- җиденче, берәр, укымыйча, кызчык;
- карый, укыса, сандугачтай, җиңел.

8. Бирелгән текстгагы ничә сүздә кисәкчә бар?

*Килче, илче, миңа хәбәр бирче:*

*“Яшь игенче килә”, – дигенче.* **(***М. Фәйзи)*

- өч;
- дүрт;
- биш;
- дөрес җавап бирелмәгән.

**II. Текстны татарчага тәрҗемә итегез.**

Любить свою семью, свои впечатления детства, свой дом, свою школу, свое село, свой город, свою страну, свою культуру и свой язык, весь земной шар необходимо… Если человек не любит хотя бы изредка смотреть на старые фотографии своих родителей, не ценит память о них, оставленную в саде, который они возделывали, в вещах, которые им принадлежали, значит, он не любит их. Если человек не любит старые дома, старые улицы, пусть даже и плохонькие, значит, у него нет любви к своему городу. Если

человек равнодушен к памятникам истории своей страны, значит, он равнодушен к своей стране. *(По Д. Лихачеву)*

**III. Иҗади бирем.**

1. Бирелгән хәрефләрнең барысын да файдаланып, сыйфат сүз төркеменә кергән бер кушма сүз язгыз.

**Р К С Т Т**

**А О И М**

2. Шигырьне укыгыз. Сораулар һәм биремнәрне үтәгез.

*Тарихым истәлеге син,*

*Болгарым истәлеге.*

*Гасырлар аша үтелгән*

*Юлларым истәлеге. (Х. Туфан)*

○ Текстта ничә исем бар?

○ Сыйфат фигыльне табып язгыз.

○ Тамыр+бәйләгеч кушымча+ясагыч кушымча+бәйләгеч кушымча схемасына туры килгән сүзне язгыз.

3. 10 җөмлә күләмендә “Кышкы табигать” исемле хикәя языгыз.